**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 13 февралендәге 436 номерлы карары**

## Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында

1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы «Җирләү һәм җеназа эше турында»гы, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2026 елның 23 гыйнварындагы 30 номерлы «2026 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе коэффициентын раслау турында»гы карары нигезендә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен 2026 елның 1 февраленнән әлеге карарга 1 һәм 2 номерлы кушымталар нигезендә 9678 сум 63 тиен күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 13 февралендәге 476 номерлы «Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында»гы карарын гамәлдән чыккан дип танырга.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.Ә.Гыйниятуллинга йөкләргә.

**Җитәкче вазифаларын башкаручы –**
**беренче урынбасар** **А.Р.Нигъмәтҗанов**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 13 февралендәге
436 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**2026 елның 1 февраленнән Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр (табутта җирләү) бәясе**

| **Хезмәтнең атамасы** | **Хезмәтнең бәясе, сумнарда** |
|---|---|
| Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| Табутны һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны бирү һәм китереп бирү | 3155,90 |
| Мәрхүмнең гәүдәсен (гәүдә калдыкларын) зиратка алып бару (3,00 сәгать исәбеннән) | 2169,22 |
| Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 4353,51 |
| **БАРЛЫГЫ** | **9678,63** |

_________________

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 13 февралендәге
436 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**2026 елның 1 февраленнән Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр (кәфенләп җирләү) бәясе**

| **Хезмәтнең атамасы** | **Хезмәтнең бәясе, сумнарда** |
|---|---|
| Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| Кәфенләү | 1873,98 |
| Җирләү өчен кирәкле предметларны бирү һәм китереп бирү | 851,08 |
| Мәрхүмнең гәүдәсен (гәүдә калдыкларын) зиратка алып бару (3,00 сәгать исәбеннән) | 2169,24 |
| Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 4784,33 |
| **БАРЛЫГЫ** | **9678,63** |

__________________